**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.07.2025 № 772

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан халыкка күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Халыкның торак-коммуналь хезмәтләргә түләү мөмкинлеген исәпләү методикасын раслау турында” 1998 елның 11 ноябрендәге 12 номерлы Россия Федерациясе Дәүләт төзелеше карары нигезендә, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык идарәче компаниясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан бирелгән шәһәр мунчасы чыгымнарын үстерү исәбе белән танышканнан соң, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифларны әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 15 июлендәге 772 номерлы карарына кушымта

**РАСЛАНДЫ**
Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 15 июлендәге 772 номерлы карары белән

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе»җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар**

| №№ тс | Мунча хезмәтләре күрсәтү, категорияләр | Юыну вакыты, сәгать | Хезмәтләр бәясе, сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Пенсионерлар һәм инвалидлар пенсия таныклыгы һәм (яисә) пенсия билгеләү турында белешмә булганда | 1 | 300,00 |
| | | 2 | 470,00 |
| 2 | Эшләүчеләргә | 1 | 350,00 |
| | | 2 | 630,00 |
| 3 | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге ата-аналары (туганнары) белән мунчага йөрүче балалар | | 175,00 |
| | **Хезмәтләрне түләүсез күрсәтү** | | |
| 1 | Бөек Ватан Сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга тиңләштерелгән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә | | |
| 2 | Пенсионерлар һәм инвалидлар декадасында Нурлат муниципаль районы территориясендә яшәүче пенсионерларга һәм инвалидларга, | | |
| 3 | Әти-әниләре (туганнары)белән мунчага йөрүче 3 яшькә кадәрге балаларга | | |
| | **Эш графигы** | **10:00 до 20:00** | |
| | | | |
| | **Дүшәмбе** | **Санитар көн** | |